**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨҖЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422008, Таш-Чишмә авылы, М.Горький урамы, 30
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

**СОВЕТ УЗЮМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422008, село Таш-Чишма, Ул. М.Горького, д.30
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

# КАРАР

26.10.2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге **Иске Өҗем** торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 08.11.2020 ел Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 08 ноябрь 2020 ел 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны – Иске Өҗем авылы, Татарстан ур. 18 йорт, Иске Өҗем авылы клубы;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итергә:
- 2022 елның 02 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Таш-Чишмә авылы, М.Горький урамы, 29нчы йорт;
- сайлау хокукына ия булган Иске Өҗем торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Иске Өҗем торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итергә;

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:
"Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Иске Өҗем торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чабу, транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү);

2) Иске Өҗем торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муницпаль берәмлекләре порталында “Интрернет” мәгълүмат-телекоммуникаөия челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Иске Өҗем авылы стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Өҗем авыл җирлеге җитәкчесе: А.Т. Вәлиев